РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Село Янурусово, улица Ленина, дом 43в, 423370 Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
Ленин урамы,43 в йорт, Янурыс авылы, 423370 Телефон: 4-10-19

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 12 14 август 2023 ел

җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 06 февралендәге 16091815201700011 номерлы хокукый экспертизасы, Сарман районы прокуратурасының 22.02-07-01 номерлы протесты, Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәрварислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, яисә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, яисә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яисә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч ел вакыт узгач;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. « «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимка һәм штрафлар буенча түләнүгә һәм бурычларын бетерүгә ышанычсыз дип тану тәртибе турында» 2017 елның 15 июнендәге 10 номерл ыкарарына үзгәреш кертү хакында» Янурыс авыл җирлеге Советының 2022 елның 16 декабрендәге 23

номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга, шулай ук Сарман муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Янурыс авыл җирлеге
Советы Рәисе А. А. Мөхәммәдиева